СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ул.Центральная, д. 2А, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк урамы, 2А йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (843665-07-35). E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

**Урта Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 35**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Советының 22.10.2018 ел, №72 карарына үзгәрешләр кертү турында (21.12.2018 ел, №83 18.12.2020 № 16 үзгәрешләр белән)**

«Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Советының 22.10.2018 ел, №72 карарына (21.12.2018 ел, №83 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар (алга таба - җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл
җирлеге башлыгы: Батталова Р.Х

СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕАТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1609002912